**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О мерах по реализации в Республике Татарстан Указа Президента Российской Федерации от 31 марта 2022 года № 175 «О ежемесячной денежной выплате семьям, имеющим детей»**

В целях реализации в Республике Татарстан Указа Президента Российской Федерации от 31 марта 2022 года № 175 «О ежемесячной денежной выплате семьям, имеющим детей» **постановляю:**

1. Передать Пенсионному фонду Российской Федерации полномочия Республики Татарстан по осуществлению ежемесячной денежной выплаты на ребенка в возрасте от восьми до семнадцати лет, установленной с 1 апреля 2022 года Указом Президента Российской Федерации от 31 марта 2022 года № 175 «О ежемесячной денежной выплате семьям, имеющим детей» (далее соответственно – ежемесячная выплата, Указ Президента Российской Федерации).

2. Установить, что предоставление ежемесячной выплаты осуществляется в порядке и на условиях, предусмотренных постановлением Правительства Российской Федерации от 9 апреля 2022 года № 630 «Об утверждении основных требований к порядку и условиям предоставления ежемесячной денежной выплаты на ребенка в возрасте от 8 до 17 лет, примерного перечня документов (сведений), необходимых для назначения указанной ежемесячной выплаты, и типовой формы заявления о ее назначении» (далее – постановление Правительства Российской Федерации).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

заключить с Пенсионным фондом Российской Федерации соглашение о предоставлении субвенции из бюджета Республики Татарстан бюджету Пенсионного фонда Российской Федерации для осуществления полномочий Республики Татарстан, переданных в соответствии с пунктом 1 настоящего Указа;

в срок до 1 мая 2022 года обеспечить возможность обращения граждан за назначением ежемесячной выплаты через многофункциональные центры предоставления государственных и муниципальных услуг в Республике Татарстан или с использованием федеральной государственной информационной системы «Единый портал государственных и муниципальных

услуг (функций)», в том числе без истребования от граждан документов, находящихся в распоряжении органов, предоставляющих государственные услуги, органов, предоставляющих муниципальные услуги, иных государственных органов, органов местного самоуправления и подведомственных государственным органам или органам местного самоуправления организаций;

предусматривать начиная с 2022 года ежегодное выделение бюджетных ассигнований из бюджета Республики Татарстан на финансирование расходов, связанных с реализацией Указа Президента Российской Федерации, с учетом уровня софинансирования расходных обязательств субъектов Российской Федерации на осуществление ежемесячной выплаты в соответствии с правилами формирования, предоставления и распределения субсидий из федерального бюджета бюджетам субъектов Российской Федерации;

принять иные решения, необходимые для реализации постановления Правительства Российской Федерации и настоящего Указа.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
16 апреля 2022 года
№ УП-285

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында**

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 175 номерлы Указы нигезендә сигез яшьтән алып унҗиде яшькә кадәрге балалар өчен 2022 елның 1 апреленнән билгеләнгән айлык акчалата түләүне (алга таба тиешенчә – айлык түләү, Россия Федерациясе Президенты Указы) башкару буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен Россия Федерациясе Пенсия фондына тапшырырга.

2. Айлык түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «8 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалар өчен айлык акчалата түләүне башкару тәртибенә һәм шартларына төп таләпләрне, әлеге айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (мәгълүматларның) үрнәк исемлеген һәм аны билгеләү турында гаризаның үрнәк формасын раслау хакында» 2022 елның 9 апрелендәге 630 номерлы карарында (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Указның 1 пункты нигезендә тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен үтәү өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына субвенция бирү турында Россия Федерациясе Пенсия фонды белән килешү төзергә;

2022 елның 1 маена кадәр гражданнарның Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре яисә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша айлык түләүләрне билгеләүне сорап, шул исәптән гражданнардан дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә

органнары карамагындагы оешмаларның эш документлары булып торган документларны таләп итмичә, мөрәҗәгать итә алуын тәэмин итәргә;

2022 елдан башлап ел саен Россия Федерациясе Президенты Указын гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауга Россия Федерациясе субъектларының чыгымнар буенча йөкләмәләрен уртак финанслау күләмен исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләрне формалаштыру, аларны бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә айлык түләүләрне башкаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирүне күздә тотарга;

Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын һәм әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 16 апрель
№ ПУ-285